КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 2 апрель

г.Казань

№ 250

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 июль, 455 нче, 2016 ел, 3 октябрь, 701 нче, 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче, 2017 ел, 13 ноябрь, 866 нчы; 2018 ел, 20 февраль, 102 нче, 2019 ел, 25 февраль, 125 нче, 2019 ел, 05 сентябрь, 775 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1.1 пунктта «****» астөшермәдә «а» – «д» пунктчаларында» сүзләреннән соң «һәм «ж» сүзләрен өстәргә;

3.3.1 пунктының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчедән социаль хезмәт күрсәтүләргә ихтыяҗ арткан очракта, социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларны социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүче тарафыннан формалаштырыла торган чират нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3.3.2 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы һәр кешегә социаль хезмәт күрсәтүгә кабул иткәндә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча реабилитация картасы төзелә. Социаль хезмәт күрсәтү тәмамланганнан соң, тернәкләндерү картасы социаль хезмәтләрдән файдаланучының шәхси эшенә кушыла.»;

3.4.2 пунктның өченче абзацында "инвалидны (инвалид баланы) реабилитацияләү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында тормыш эшчәнлегенең төп категорияләрен 2, 3 дәрәҗә чикләүләре булган" сүзләрен төшереп калдырырга».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин